**«РАСЛЫЙМ»**

**Татарстан Республикасы**

**Премьер-министры**

**урынбасары – министр**

**________________ Р.Т.Борhанов**

**«23» октябрь 2020 нче ел**

**Туган телдә белем бирү мәктәпләре укучылары өчен**
**2020 нче елда туган (татар) әдәбияттан**
**дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру өчен**
**контроль-үлчәү материалларының үзенчәлекләре (спецификация)**

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением
высшего профессионального образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**1. Имтихан эшенең максаты**

Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе стандартлаштырылган биремнәр (контроль бәяләү материаллары) ярдәмендә укучыларның әзерлек сыйфатын объектив бәяләүне күздә тота.

Контроль бәяләү материаллары 9 нчы сыйныфны тәмамлаучы укучыларның татар әдәбиятыннан белем дәрәҗәсен билгеләү мөмкинлеген бирә.

**2. Имтихан эшенең эчтәлеген билгеләүче документлар**

Имтихан эшенең эчтәлеге түбәндәге документларга нигезләнеп билгеләнә. Татар әдәбиятыннан федераль исемлеккә кергән дәреслекләр, федераль исемлектәге нәшриятлар чыгарган уку әсбаплары:

1. Татар телендә белем бирүче мәгариф оешмалары өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа (1 – 11 сыйныфлар өчен) / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова, Ф.Ф.Хәсәнова // http://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_1128131.pdf
2. Әдәбият: туган телдә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслекләр (5 – 9 нчы сыйныфлар). – Казан: Татар.кит.нәшр., 2014-2016.
3. Татар урта төп белем бирү мәктәпләренең 5-9 нчы классларында укучы татар балаларының татар әдәбиятыннан белемнәрен бәяләү нормалары.

**3. Имтихан эшенең төзелешен һәм эчтәлеген билгеләү принциплары**

Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенең төзелеше һәм эчтәлеге рус әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе (ОГЭ) һәм 2020 нче елда уздырылган татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе тәҗрибәсенә таянып эшләнде. Имтихан эшенең формасы һәм төзелеше, биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе төп гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар әдәбияты курсының төрле баскычларын яктырта. Аның эчтәлеге укучыларның татар әдәбиятыннан теоретик һәм гамәли белем дәрәҗәсен, күнекмәләрен бәяләргә мөмкинлек бирә.

Шул рәвешле татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе имтихан тапшыручылардан иҗади фикерләүне, әсәрне анализлау юлларын камилләштерүне, әдәби әсәрдәге үзенчәлекләрне бәяләү күнекмәләрен активлаштыруны таләп итә.

**4. Имтихан эшенең төзелеше**

Укучы, әдәбияттан имтиханга әзерләнү барышында, төп (тулы булмаган) гомуми мәҗбүри белем бирү эчтәлегендә билгеләнгән материалны, уку дәверендә әлеге предметтан үзләштергән-өйрәнгәннәрен кабатларга тиеш.

2020 нче елгы дәүләт йомгаклау аттестациясеннән контроль бәяләү материаллары укучының белем дәрәҗәсен төрле яклап билгеләүче <u>ике бүлектән</u> тора.

Беренче бүлектә мәҗбүри белем бирү эчтәлегендә билгеләнгән әсәрләргә анализ ясау тәкъдим ителә. Ул ике альтернатив варианттан тора, укучы үзе теләгән бер вариантны сайлап алу хокукына ия. Беренче вариантка эпик яки драма әсәреннән өзек тәкъдим ителә, икенче вариант лирик әсәргә кагылышлы биремнәрне актырта. Һәр вариантта 3 бирем күрсәтелә, аларның беренче икесе тәкъдим ителгән аспектта әсәргә өлешчә анализ ясауны таләп итә, өченчесе исә ике әсәрне бәяләп, чагыштырма аспектта җавап язуны сорый.

Бу бүлекләрдә укучының әдәби әсәрләрнең эчтәлегенә караган төп төшенчәләрне, сыйфатларны (темасын һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны, сюжет һәм сюжет элементларын, образлар системасын, әдәби алымнарны, тел-сурәтләү чараларын һ.б.) дөрес билгели белү дәрәҗәсе тикшерелә. Анализ өчен тәкъдим ителгән текстлар укучының әсәрнең сюжетын белү дәрәҗәсен ачыклаудан бигрәк, әдәби текстка анализ ясау мөмкинлекләрен билгеләүгә йөз тота.

Эшнең икенче бүлегендә билгеләнгән дүрт теманың берсенә сочинение язу сорала, бу очракта укучының билгеле бер әдәби әсәр (әсәрләр) турында тупланма фикере, билгеләнгән үзенчәлекне аңлата белү сәләте тикшерелә. Эшнең мондый эзлеклелектә оештырылуы әсәрдән алынган өзекнең тексттагы урынын, әсәрнең сюжет-композицион, тема-проблема, тел-стиль үзенчәлекләрен билгеләү, укучының геройларга карата үз фикерен җиткерә алу мөмкинлеген бирә. Бу сораулар укучыларның әдәбият тарихындагы бер әсәргә бәя бирүен күздә тота.

Укучы ике сорауның берсен генә сайлап ала һәм, үз дәлилләре белән баетып, шуңа җавап яза.

Проблемалы сораулар укучының тормышны танып-белү, логик һәм иҗади фикерләү, фикерен дәлилли алу дәрәҗәсен ачарга ярдәм итә, аңа сочинение формасында үз мөнәсәбәтен җиткерү мөмкинлеген бирә.

Түбәндә имтихан эше биремнәренең өлешләргә бүленешен схематик формада чагылдырган таблица тәкъдим ителә.

*1 нче таблица*

**Имтихан эшендәге биремнәрнең бүлекләргә бүленеше**

| Эшнең бүлекләре | Биремнәрнең саны | Беренчел максималь балл | Биремнәрнең төре |
|---|---|---|---|
| 1 нче бүлек | 2 | 6 | 3-5 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап сорала |
| | 1 | 5 | Чагыштырма аспектта 5-8 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап сорала |
| 2 нче бүлек | 1 | 12 | 200 сүздән дә ким булмаган сочинение язу сорала |
| | **4** | **23** | **100 %** |

**5. Эчтәлекнең, элементларына карап, биремнәргә бүленеше**

Имтихан эшенең эчтәлеге һәм төзелеше укучының әдәбияттан алган белемнәрен (әдәбият тарихы һәм теориясе) бәяләргә һәм предмет буенча эшли алу сәләтен билгеләргә мөмкинлек бирә:

– әдәби текстка төр яки жанр үзенчәлекләреннән чыгып анализ ясый белүен;

– үз фикерен җиткерә алуын;

– әдәби әсәрнең темасын, идеясен, автор күтәргән проблемаларны дөрес билгели алуын, геройга характеристика бирү мөмкинлеген;

– әдәби әсәрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен, әсәрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын билгели алуын;

– әсәрләргә язма интерпретация (шәрехләмә) бирү үзенчәлеген;

– әсәрдә автор позициясен билгели алуын;

– укылган әсәргә карата үз мөнәсәбәтен язма формада бирә, сочинение яза алуын.

**6. Биремнең катлаулылык дәрәҗәсенә карап бүленеше**

Имтихан эшенә катлаулылыгы ягыннан өч төрле бирем тәкъдим ителә: 1 нче бүлектә бирелгән 1.1.1., 1.1.2. һәм 1.2.1., 1.2.2. биремнәре 5 – 8 нче сыйныфларда үтелгән материалдан алына, 1.1.3. һәм 1.2.3. биремнәре өлешчә катлауландырылган, 2 нче бүлектәге бирем катлаулы бирем дип санала, ул әдәбият тарихына бәйле куела һәм сочинение язуны сорый. Имтихан бирүчегә тәкъдим ителгән дүрт теманың **б е р с е н г е н ә** сайлап алу һәм шуңа җавап язу мөмкинлеге бирелә. Бу очракта имтихан тапшыручы, мөстәкыйль рәвештә, әдәби темага эчтәлеге белән туры килгән, мәгънәви яктан эзлекле текст яза белүен күрсәтергә тиеш.

*3 нче таблица*

**Биремнең катлаулылыгы ягыннан бүленеше**

| **Катлаулылык дәрәҗәсе** | **Биремнәрнең саны** | **Беренчел максималь балл** | **Тулы эш өчен бирелгән максималь баллның беренчел эшкә карата проценты (=39%)** |
|---|---|---|---|
| База өлеше (1.1.1., 1.1.2. һәм 1.2.1., 1.2.2.) | 2 | 6 | 26 % |
| Өлешчә катлаулан-дырылган (1.1.3. һәм 1.2.3.) | 1 | 5 | 22 % |
| Катлаулы (.2.1 – 2.4.) | 1 | 12 | 52 % |
| **Барлыгы:** | **4** | **23** | **100 %** |

**7. Имтихан эшен башкару өчен 210 минут вакыт бирелә.**

Эшнең беренче бүлегендәге биремнәрне башкару өчен (эпик яки драма әсәре алынган өзеккә анализ ясауга) – 120 минут, икенче бүлекне үтәүгә калган вакыт күздә тотыла.

**8. Аерым биремнәрне һәм тулаем эшне бәяләү.**

Имтихан эшенең 1 нче бүлегендәге 1.1.1, 1.1.2. һәм 1.2.1., 1.2.2. биремнәрен (3-5 җөмлә күләмендә) бәяләү 2 критерий нигезендә алып барыла һәм **3 балл** белән бәяләнә.

Чагыштырма пландагы 1.1.3. һәм 1.2.3. биремнәре 5-8 җөмлә күләмендә) 3 критерий нигезендә бәяләнә һәм дөрес җавабы өчен укучы **биш балл** ала.

Биремгә чикле күләмдәге текст белән җавап язылган эшне экспертлар бәяли. Бәяләү барышында “фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы” һәм “сөйләм нормаларына туры килүе” критерийлары үзәккә куела, сөйләм ягыннан оештырылышына игътибар ителә.

2.1. – 2.4. биремнәренең берсен, сайлап алып, сочинение язу күздә тотыла, биш критерий нигезендә **12 балл** куела. Әгәр имтихан бирүче беренче критерий буенча (эчтәлек ягы) **0 балл** алса, өченче өлештәге бирем үтәлмәгән булып санала.

Имтихан нәтиҗәләре 100 баллык шкала белән бәяләнә.